ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) үз компетенциясе чикләрендә хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын кабул итү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге вәкаләтле органын билгеләү;

3) хайваннар приютлары эшчәнлеген оештыру һәм аларда хайваннарны тоту нормалары буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган методик күрсәтмәләр нигезендә хайваннар приютлары эшчәнлеген оештыру тәртибен һәм аларда хайваннарны тоту нормаларын билгеләү;

4) хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган методик күрсәтмәләр нигезендә хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

5) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

6) этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү тәртибен һәм этне теркәү турында таныклык рәвешен билгеләү;

7) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәүне гамәлгә ашыру;

2) Федераль законның 16 статьясындагы 10 өлеше нигезендә хайваннар приютына китерелгән хуҗасыз йорт хайваннары һәм хуҗалары милек хокукыннан баш тарткан хайваннар турында өстәмә белешмәләр исемлеген һәм шушы белешмәләрне приют хезмәткәрләре тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау;

3) хуҗасыз йорт хайваннарын аулаучы индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар тарафыннан хуҗасыз йорт хайваннарын аулау процессының видеоязмасын тапшыруны, шулай ук хуҗасыз йорт хайваннарын аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтаручы индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар тарафыннан хуҗасыз йорт хайваннарын кайтару процессының видеоязмасын тапшыруны соратып алу;

4) хуҗасыз йорт хайваннарын аулаучы индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар тарафыннан башкарылган эшләр күләме турында белешмәләр тапшыруны соратып алу;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең региональ дәүләт ветеринария күзәтчелеген, региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнары хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген башкаралар.

5 статья. **Хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында Россия Федерациясе законнары һәм Федераль закон нигезендә билгеләнә.

2. Җирле үзидарә органнары, аларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән очракта, күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

6 статья. **Татарстан Республикасының аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 7 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3, № 7);

2) «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июлендәге 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7).

7 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 27 декабрь
№ 120-ТРЗ